КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 октябрь г.Казань № 929

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар мәйданын булдыру, арттыру яки аларны реиндустриализацияләү проектларын төбәк буенча сайлап алуны үткәрү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2024 ел, 4 сентябрь, 723 нче карары белән расланган Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар мәйданын булдыру, арттыру яки аларны реиндустриализацияләү проектларын төбәк буенча сайлап алуны үткәрү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар мәйданын булдыру, арттыру яки аларны реиндустриализацияләү проектларын төбәк буенча сайлап алуны үткәрү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2024 ел, 4 сентябрь, 723 нче карары белән расланган Индустриаль (сәнәгать) парклар, сәнәгать технопарклары, югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар мәйданын булдыру, арттыру яки аларны реиндустриализацияләү проектларын төбәк буенча сайлап алуны үткәрү тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуда катнашучының әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән таләпкә туры килүе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 241 статьясындагы 15 пункты нигезләмәләренең Россия юридик затларына бирелә торган субсидияләргә һәм бюджет инвестицияләренә кагылмавы

турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2024 елның 17 июнендәге 813 номерлы карары нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.»;

2.3 пунктның сигезенче абзацында «әлеге Тәртипнең 2.2 пунктындагы унберенче абзацын исәпкә алып,» сүзләрен өстәргә;

2.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.2 пунктындагы икенче һәм унберенче абзацларында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат бирелгән кушымта.».

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

әлеге карарның гамәле 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин